ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**08.10.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№1922**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Большие Ключи авыл җирлегенең генераль планы проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында » 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, территорияләрне социаль, икътисадый, экологик һәм башка факторлардан чыгып билгеләү максатларында, авыл җирлеге территориясенең тотрыклы үсешен тәэмин итү, бу территориянең комплекслы үсешен уңайлы тормыш шартлары белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирүче инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерү, гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Большие Ключи авыл җирлегенең Генераль планы проектын әзерләүгә керешергә.
2. Большие Ключи авыл җирлегенең Генераль планы проектын әзерләү буенча комиссия төзергә, аның составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Большие Ключи авыл җирлегенең Генераль планы проектын әзерләү буенча комиссия турында нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга.
4. Комиссиягә 2020 елның 31 октябренә кадәр Большие Ключи авыл җирлегенең Генераль планы проектын әзерләү эшләрен, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган тәртиптә, алып барырга.
5. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Большие Ключи авыл җирлегенең Генераль планы проектын әзерләү турында хәбәрне «Интернет»челтәрендәге Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А. В. Старостин

ЗМР Башкарма комитеты карары буенча
1 нче кушымта
08.10.2020 ел №1922

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОЛЬШИЕ КЛЮЧИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ГЕНЕРАЛЬ ПЛАН ПРОЕКТЫН ӘЗЕРЛӘҮ ТУРЫНДА КОМИССИЯ СОСТАВЫ

**Комиссия рәисе:**

| | |
|---|---|
| Старостин А. В. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары; |

**Комиссия рәисе урынбасары:**

| | |
|---|---|
| Сергеев П.Н.<br>сәясәте | «ЗМР архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» МБУ җитәкчесе; |

**Комиссия секретаре:**

| | |
|---|---|
| Левочкина Н.Н. | «ЗМР архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе » МБУ генераль план бүлек начальнигы; |

**Комиссия әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Комягин С. Е. | Большие Ключи авыл җирлеге башлыгы; |
| Алексахина А. Ю. | «ЗМР мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ җитәкчесе; |
| Нургалиева Э. Ә. | Зеленодольск муниципаль районы Советының юридик бүлеге начальнигы; |

ЗМР Башкарма комитеты карары буенча
2 нче кушымта
08.10.2020 ел №1922

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОЛЬШИЕ КЛЮЧИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ГЕНЕРАЛЬ ПЛАНЫ ПРОЕКТЫН ӘЗЕРЛӘҮ КОМИССИЯСЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Большие Ключи авыл җирлегенең Генераль планы проектын әзерләү комиссиясе (алга таба - комиссия) территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыру нигезендә территорияләрнең тотрыклы үсешен тәэмин итү өчен төзелә.

1.2. Комиссия үз эшчәнлеген РФ Шәһәр төзелеше кодексы, башка норматив актлар нигезендә даими эшләп килә һәм тормышка ашыра.

1.3. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе законнарына, «Большие Ключи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.4. Комиссия дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, муниципаль предприятиеләр, учреждениеләр, шулай ук кызыксынучы юридик һәм физик затлар белән үзара хезмәттәшлектә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра.

## 2. КОМИССИЯ СОСТАВЫ

2.1. Комиссия составы ЗМР Башкарма комитеты карары белән раслана.
2.2. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазифаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

## 3. КОМИССИЯ КОМПЕТЕНЦИЯСЕ

3.1. Комиссия компетенциясенә түбәндәгеләр керә:
3.1.1. Территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыру нигезендә территорияләр үсешен эзлекле Формалаштыру һәм камилләштерү процессын оештыру, шул исәптән Зеленодольск муниципаль районының «Большие Ключи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге генераль планына үзгәрешләр кертү;
3.1.2. Зеленодольск муниципаль районы «Большие Ключи авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә, гражданнарның һәм юридик затларның тәкъдимнәрен карау;
3.1.3. Зеленодольск муниципаль районы «Большие Ключи авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү;

3.1.4. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә бирү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә тәкъдимнәр әзерләү.

## 4. КОМИССИЯ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТӘРТИБЕ

4.1. Комиссия кирәк булган саен, ләкин кварталга кимендә бер тапкыр җыела.
4.2. Комиссия утырышы, әгәр Комиссия әгъзаларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.
4.3. Комиссия карары комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәис тавышы хәлиткеч булып тора.
4.4. Гражданнарның һәм юридик затларның тәкъдимнәре комиссия рәисе исеменә җибәрелә. Комиссия рәисе аларны комиссия утырышларында ике атна дәвамында карап тикшерүне тәэмин итә.
4.5. Күрсәтелгән тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре буенча 4.4 пунктта карар кабул ителә, ул беркетмәдә чагылдырыла.